КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2020 ел, 11 февраль

г.Казань

№ 89

Диспансер күзәтүендә булган югары риск пациентларында йөрәк-кан тамырлары авыруларын һәм йөрәк-кан тамырлары өзлегүләрен профилактикалауны тәэмин итү чараларын тормышка ашыруга Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 ел, 30 ноябрь, 1569 нчы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Диспансер күзәтүендә булган югары риск пациентларында йөрәк-кан тамырлары авыруларын һәм йөрәк-кан тамырлары өзлегүләрен профилактикалауны тәэмин итү чараларын тормышка ашыруга Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен расларга.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 11 февраль, 89 нчы
карары белән расланды

Диспансер күзәтүендә булган югары риск пациентларында йөрәк-кан тамырлары авыруларын һәм йөрәк-кан тамырлары өзлегүләрен профилактикалауны тәэмин итү чараларын тормышка ашыруга Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Сәламәтлек саклау» илкүләм проектының «Йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәш» федераль проектының максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итүче амбулатор шартларда баш мие кан әйләнешенең кискен бозылуын, миокард инфаркты һәм башка кискен йөрәк-кан тамырлары авырулары, дару препаратлары белән тәэмин итү буенча төбәк проектларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чараларны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү механизмын билгели.

2. Бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга кадәр Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карары белән расланган «2025 елга кадәр Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчалары һәм күрсәтелгән чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган федераль бюджеттан субсидияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыруга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүче – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы бер ел дәвамында амбулатор шартларда дару препаратлары белән тәэмин итүгә бәйле Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс ягыннан тәэмин итүгә Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган исемлек нигезендә, баш мие кан әйләнешенең кискен бозылуын, миокард инфарктын кичергән, шулай ук аортокоронар шунтлау, коронар артерияләрнең ангиопластикасын һәм йөрәк-кан тамырлары авыруларына бәйле катетер абляциясе ясалган затлар, әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән затлардан тыш акчасын җибәрә.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән акчалар Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы раслаган исемлек нигезендә «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон

нигезендә медицина куллану өчен дару препаратлары белән тәэмин итү рәвешендә социаль хезмәт күрсәтүгә хокуклы амбулатор шартларда бер ел дәвамында дару препаратлары белән тәэмин итүгә, баш мие кан әйләнешенең кискен бозылуын кичергән затлар, миокард инфарктын, шулай ук стенировкалы аортокоронар шунтлау, коронар артерияләрнең ангиопластикасын һәм йөрәк-кан тамырлары авыруларына бәйле катетер абляциясе ясалуга юнәлдерелә алмый.

5. Акчаларны тоту Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган шәхси исәп аша гамәлгә ашырыла.

6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына финанслауның иң чик күләмнәрен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан финанслауның иң чик күләмнәрен җиткергәннән соң расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җиткерә.

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы:

әлеге Тәртипнең 4 пункты нигезендә дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт контрактларын (шартнамәләрен) төзи;

дәүләт контрактлары (шартнамәләре) шартларына туры китереп, дару препаратларын сатып алуга дәүләт контрактлары (шартнамәләре) төзелгән оешмаларга акча күчерә.

8. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына билгеләнгән срокларда Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына диспансер күзәтүендә булган пациентларда йөрәк-кан тамырлары авыруларының һәм йөрәк-кан тамырлары авыруларының профилактикасын тәэмин итүгә федераль бюджеттан субсидияләр бирү турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча хисаплар тапшыра.

9. Акчаларны максатсыз файдалану Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка китерә.

10. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмаган калган акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән таләпләр нигезендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

_______________________________